ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ГОРОДА НИЖНЕКАМСКА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

пр. Строителей, д. 12, г. Нижнекамск, 423570

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ТҮБӘН КАМА ШӘҺӘРЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

Төзүчеләр пр., 12 нче йорт, Түбән Кама шәһәре, 423570

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

№ 35 25 февраль 2019 ел

# Салым салынырга тиешле гражданнар кеременең һәм мөлкәт хакының иң чик күләмнәрен билгеләү турында

«Татарстан Республикасы дәүләт торак фондыннан һәм муниципаль торак фондыннан социаль наем шартнамәләре буенча гражданнарның аларга торак урыннары бирү хокукларын гамәлгә ашыру турында» 2007 елның 13 июлендәге 31-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, гаиләнең һәр әгъзасына яисә ялгыз яшәүче гражданга туры килә торган һәм күрсәтелгән законга кушымтада бәян ителгән салым салынырга тиешле керемнең иң чик күрсәткечләрен билгеләү методикасы нигезендә, карар бирәм:

1. Гражданнарны аз керемлеләр дип тану һәм муниципаль торак фондыннан социаль наем шартнамәләре буенча аларга торак урыннары бирү турында карар кабул итү өчен түбәндәге чик күрсәткечләре билгеләргә:

1.1. Гаиләнең һәр әгъзасына туры килә торган уртача айлык җыелма керемнең күләме:

1.2.1. Ялгыз кеше өчен – 29 451,50 сум;

1.2.2. Ике кешелек гаилә өчен – 18 741,80 сум;

1.2.3. Өч кешелек һәм аннан күбрәк кешелек гаилә өчен – 16 064,40 сум.

1.2. Гаилә әгъзалары (ялгыз яшәүче граждан) милкендәге һәм салым салынырга тиешле мөлкәт хакының иң чик күләме:

1.2.1. Ялгыз яшәүче кеше өчен – 1 200 045 сум;

1.2.2. Ике кешелек гаилә өчен – 1 527 330 сум;

1.2.3. Өч кешелек гаилә өчен – 1 963 710 сум;

1.2.4. Дүрт кешелек гаилә өчен – 2 618 280 сум;

1.2.5. Биш кешелек гаилә өчен – 3 272 850 сум.

2. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Түбән Кама шәһәре башкарма комитетының торак сәясәте бүлеге җитәкчесе И.Н.Бәдретдиновка йөкләргә.

Җитәкче Д.И. Баландин